ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

05 декабрь 2025ел | № 10224

«2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасы турында

Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрнең хәзерге һәм киләчәк буыннары сәламәтлегенең югары дәрәҗәсенә ирешү, шул исәптән халыкның үз сәламәтлегенә карата җаваплы мөнәсәбәтен формалаштыру, Яр Чаллы шәһәрендә сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатларында, шәһәр Уставының 53 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 5 декабрендәге
10224 номерлы карарына
кушымта

«2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту»
муниципаль программасы

1 бүлек. «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту»
муниципаль программасының паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2026-2030 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге халкы арасында җәмәгать сәламәтлеген ныгыту» муниципаль программасы (алга таба – программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез (хокук актының исеме, номеры һәм датасы) | Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Бердәм халык хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясенең Милли иминлек стратегиясе |
| Программаны төп эшләүчеләр | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе |
| Программаны башкаручылар | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе, Башкарма комитетның район хакимиятләре, Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе |
| Программаның максаты | Халык сәламәтлеген, тормыш сыйфатын яхшырту, җәмәгать сәламәтлеге культурасын, сәламәтлеккә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру |
| Программаның бурычлары | 1. Халыкның сәламәт яшәү рәвеше турында хәбәрдарлыгын арттыру (дөрес туклануны, начар гадәтләрдән баш тартуны һәм даими физик активлыкны кертеп, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати кампанияләр).<br>2. Авыруларны (беренче чиратта хроник йогышлы булмаган авыруларны, шул исәптән йөрәк-кан тамырлары, сулыш органнары, онкология, шикәр диабетын) профилактикалау.<br>3. Физик активлыкны арттыру (спорт һәм физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, спорт чаралары оештыру, актив яшәү рәвешен пропагандалау).<br>4. Профилактик медицина ярдәменнән (профилактик медицина |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | тикшеруләреннән, диспансеризациядән, вакцинациядән һәм медицина ярдәменең башка төрләреннән) файдалану мөмкинлеге.<br>5. Куркыныч факторларыны, шул исәптән тәмәке тартуны, алкоголь һәм наркотик чаралар куллануны, дөрес тукланмауны, физик активлык җитәрлек булмауны кимету | | | | | | |
| Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары | 2026 – 2030 еллар | | | | | | |
| Еллар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары (мең сум) | Программаны тормышка ашыру еллары | | | | | |
| | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - | - | - |
| | Барлыгы | - | - | - | - | - | - |
| Программаны тормышка ашыруның көтелгән нәтиҗәләре һәм нәтиҗәлелек күрсәткечләре | 1. Халыкның гомер озынлыгын арттыру;<br>2. Халыкны диспансеризациягә җәлеп итүне арттыру;<br>3. 3 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган халыкның гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче гражданнарның өлешен арттыру | | | | | | |
| Программаны тормышка ашыруга контрольне оештыру системасы | Программаның үтәлешенә контрольне Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе гамәлгә ашыра. | | | | | | |

## 2 бүлек. Проблеманың әчтәлеге һәм аны программа методы белән хәл итү кирәклеген нигезләү

Программа «Дәвамлы һәм актив тормыш» милли проектының «Сәламәтлек һәркем өчен» федераль проектының региональ чаралары кысаларында Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә яшәүчеләрнең сәламәтлек дәрәҗәсен арттыру, шул исәптән үз сәламәтлегенә җаваплы мөнәсәбәт булдыру, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, кеше потенциалын саклау һәм үстерү өчен шартлар тудыру максатында эшләнде.

Муниципаль программаны уңышлы тормышка ашыру нигезенә түбәндәге принциплар салынган:

- социаль статуска, керемнәр дәрәҗәсенә һәм яшәү урынына бәйсез рәвештә, халыкның барысы өчен дә программа чараларыннан файдалану мөмкинлеге булырга тиеш;
- программа чараларына халыкның барлык яшь һәм социаль төркемнәре: балалар, яшьләр, эшкә яраклы яшьтәге халык, өлкән яшьтәге гражданнар җәлеп ителергә тиеш.

Программаның актуальлеге күренеп тора, чөнки төрле чыганаклар буенча кеше сәламәтлегенә, аның гомер озынлыгына барлык йогынтыларның 60% - аның яшәү рәвеше. Сәламәтлек торышы - социаль, икътисадый һәм экологик иминлекнең мөһим күрсәткече, Яр Чаллы шәһәре халкының тормыш сыйфаты күрсәткече.

2024 ел башына шәһәрнең даими халык саны 544 383 кеше тәшкил иткән, бу 2023 ел саныннан 0,25% ка кимрәк (2023 ел - 545 750, 2022 ел - 528 366, 2021 ел - 532 074, 2020 ел - 533 839 ).

Соңгы биш елда чаллылыларның гомер озынлыгы 2,25 елга арткан (2019 ел - 75,9; 2020 ел – 72,85; 2021 ел – 71,5; 2022 ел – 77,73; 2023 ел – 78,15) һәм 2023 ел йомгаклары буенча 78,15 яшь тәшкил иткән.

2024 ел нәтиҗәләре буенча Яр Чаллы шәһәре халкының табигый кимүе күзәтелә - 1 000 кешегә минус 0,7. 2023 елда минус 0,2, 2022 елда плюс 0,1.

2024 елда халыкның үлем күрсәткече Яр Чаллы шәһәре буенча Татарстан Республикасы белән чагыштырганда 19,5% ка түбәнрәк (2024 ел – 11,3%) һәм 1 000 кешегә 9,1 тәшкил итте (2023 ел – 8,9%, 2022 ел – 9,2%).

2024 елда бөтен халык арасында беренчел авырулар саны кими һәм 821,3 тәшкил итә, 2023 ел белән чагыштырганда 1000 кешегә 892,1.

2024 елда шәһәр халкы арасында авырулар таралу 1 855,6 тәшкил иткән, 2023 ел белән чагыштырганда 3,58% ка (1 957,7) кимегән.

2024 елда авыруларның аерым социаль әһәмиятле төркемнәре буенча авырулар 100 000 кешегә түбәндәгечә тәшкил итте:

- яман шешләр - 506,4, 2023 ел белән чагыштырганда 7% ка арту күзәтелә. Соңгы 3 елда 15% ка арткан;
- туберкулез – 17,2, 3 ел эчендә 16,8 % ка кимегән;
- наркологик авырулар (шул исәптән профилактик күзәтү) - 333,7, таралуның 3 елда 10,1% ка гомуми кимүе күзәтелә;
- алкоголь психозлары 11,2 % ка кимегән (2022 ел – 49,8, 2023 ел – 58,1, 2024 ел - 58,0 авыру).

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы экспертлары бәяләвенчә, алкоголь продукциясен куллануның рөхсәт ителә торган дәрәҗәсеннән артып киту (җан башына елга 8 литр абсолют алкоголь (сусыз спирт) исәбеннән) милләт сәламәтлеге өчен бик куркыныч булып тора һәм әлеге чиктән артык кулланылган һәр литр 11 ай гомерне кыскарта. Алкоголь барлык тере күзәнәккә, бигрәк тә баш мие кабыгы күзәнәкләренә тискәре йогынты ясый.

2021-2025 елларда алкоголизм таралуны булдырмау буенча профилактик эш «2021-2025 елларга Татарстан Республикасында халыкны наркотизацияләүне профилактикалауның озак сроклы максатчан программасын» тормышка ашыру кысаларында үткәрелде, аның төп бурычларының берсе булып наркологик авыруларны иртә профилактикалауның бердәм дәүләт системасын булдыру һәм шуның нигезендә сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру тора.

Халык белән профилактик эш массакүләм мәгълүмат чаралары аша алып барылды.

Педагогларга, психологларга, мәктәп директорларының тәрбия эше һәм сәламәтлек буенча урынбасарларына; шәһәрнең белем бирү учреждениеләрендә профилактик тикшерүләрне оештыру өчен җаваплы затларга наркологик авыруларны профилактикалауны оештыру мәсьәләләре буенча 34 консультация үткәрелде.

2024 елда Яр Чаллы шәһәре халкын диспансеризацияләү һәм профилактик тикшерү нәтиҗәләре буенча хроник авырулар барлыкка килү ихтималын арттыра торган 136135 куркыныч фактор ачыкланган (рациональ булмаган туклану – 32,2%, түбән физик активлык – 28,8%, гәүдәнең артык авырлыгы һәм симерү – 14,3%), 220811 хроник йогышлы булмаган авыру теркәлгән (кан әйләнеше системасы авырулары - 45,3%, ашкайнату органнары авырулары – 4,3%, шикәр диабеты – 3,7%), шулардан беренче тапкыр 11755 авыру ачыкланган (кан әйләнеше системасы авырулары – 20,8%, ашкайнату

органнары авырулары – 16,2%, күз авырулары – 13,0%).

Күрсәтелгән мәгълүматлар гражданнарда, шул исәптән беренче тапкыр диспансеризацияләү вакытында ачыкланган, хроник йогышлы булмаган авыруларның күп булуы турында сөйли, аларның үсеше куркыныч факторларының киң таралуы, шулай ук халыкның куркыныч факторларны төзәтү кирәклеге һәм ысуллары турында белемнәренең түбән булуы сәламәтлекне ныгытуның мөһимлеген һәм кирәклеген раслый.

Йогышлы булмаган авырулардан үлүчеләр санының югары булуы медицина (шул исәптән югары технологияле) ярдәме күрсәтүгә турыдан-туры чыгымнаргә бәйле рәвештә, шулай ук вакытыннан алда үлүчеләр, инвалидлык һәм вакытлыча эшкә яраксызлык аркасында хезмәт ресурсларының кыскаруы нәтиҗәсендә икътисадый югалтуларга китерә.

Йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау һәм контрольдә тотуның нигезе булып сәламәт яшәү рәвеше тора. Сәламәт яшәү рәвеше - кешенең йогышлы булмаган авыруларның килеп чыгуын һәм үсешен кисәтүгә юнәлдерелгән һәм рациональ булмаган туклануdan, физик активлык булмаудан, шулай ук стрессларны адаптив булмаган җиңеп чыгудан гыйбарәт куркыныч факторларының тәэсирен бетерү яки киметү белән характерлана торган яшәү рәвеше.

Ачыкланган авырулар структурасында алдынгы урынны алып торган күп кенә йогышлы булмаган авырулар барлыкка килүгә йогынты ясый торган өстенлек итүче куркыныч факторлар булып гиподинамия, рациональ булмаган туклану, психик киеренкелек, стресслар, начар гадәтләр, гәүдәнең артык авырлыгы тора.

Хәзерге вакытта организмда май тукымасы күләменең патологик артуы (симерү), эстетик проблема кысаларыннан чыгып, бик күп авыр, еш кына элекке хәленә кайтмый һәм үлемгә китерә торган авырулар үсешенә сәбәп булуы шик тудырмый.

Хәзерге вакытта Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләр арасында симерүнең таралу күрсәткече 1 000 кешегә 24,7 тәшкил итә.

Төрле чыганакларның мәгълүматлары буенча, хәзерге вакытта Россиядә симерүдән интегүче кешеләрнең 95% турыдан-туры гәүдә авырлыгының артык булуына бәйле сәбәпләрдән үлә. Симерү белән авыручыларның гомер озынлыгы 10-20 елга кыскара (симерә башлау елына бәйле рәвештә).

Бүгенге халыкның һәм киләчәк буыннарның сәламәтлек дәрәҗәсен күтәрү халык сәламәтлеген ныгытуга һәм әйләнә-тирә мохитне савыктыруга юнәлдерелгән сәясәт формалаштыру, кешеләрнең үз сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирәдәгеләрнең сәламәтлегенә карата җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру аша мөмкин.

Болар барысы да комплекслы якын килүне: эшчәнлекләре тормыш сыйфатына һәм сәламәтлеккә йогынты ясый торган төрле ведомстволарны, милекнең барлык формаларындагы оешмаларны, граждан җәмгыятен берләштерүне; халык сәламәтлеге проблемаларын хәл итү максатларында аларның үзара максатчан һәм килешенгән хезмәттәшлегенең тотрыклы системасын төзүне таләп итә.

Димәк, Яр Чаллы шәһәрендә яшәүчеләрнең сәламәт яшәү рәвеше алып баруы үлүчеләр санының кимүенә, шул исәптән эшкә яраклы халык арасында, өлкәннәр һәм балалар арасында авырулар санының кимүенә, инвалидлык буенча пенсиягә вакытыннан алда чыгу ихтималының кимүенә, авыруларны кисәтүгә һәм авыруларны иртә стадияләрдә ачыклауга йогынты ясаячак. Халыкның сәламәт яшәү рәвеше, сәламәтлек саклау өлкәсендәге югары күрсәткечләр «Демография» милли проектының максатчан күрсәткеченә ирешүгә - көтелгән сәламәт гомер озынлыгының 67 яшькә кадәр артуына, күчмә миграциянең кимүенә һәм туучылар санының артуына китерәчәк, бу исә Яр Чаллы шәһәрендәге гомуми демографик хәлгә уңай йогынты ясаячак.

## 3 бүлек. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаны тормышка ашыру биш елга – 2026-2030 елларга исәпләнгән.

Муниципаль программаның максаты булып халык сәламәтлеген, тормыш сыйфатын яхшырту, җәмәгать сәламәтлеге культурасын, сәламәтлеккә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру тора.

Программаның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- халыкның сәламәт яшәү рәвеше турында хәбәрдарлыгын арттыру (дөрес туклануны, начар гадәтләрдән баш тартуны һәм даими физик активлыкны кертеп, сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга юнәлдерелгән мәгълүмати кампанияләр);
- авыруларны (беренче чиратта хроник йогышлы булмаган авыруларны, шул исәптән йөрәк-кан тамырлары, сулыш органнары, онкология, шикәр диабетын) профилактикалау;
- физик активлыкны арттыру (спорт һәм физик культура белән шөгыльләнү өчен шартлар тудыру, спорт чараларын, ял итү зоналарын оештыру, актив яшәү рәвешен пропагандалау);
- профилактик медицина ярдәменнән (профилактик медицина тикшерүләреннән, диспансеризациядән, вакцинациядән һәм медицина ярдәменең башка төрләреннән) файдалану мөмкинлеге;
- куркыныч факторларны, шул исәптән тәмәке тартуны, алкоголь һәм наркотик чаралар куллануны, дөрес тукланмауны, физик активлык җитәрлек булмауны киметү.

## 4 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген билгеләргә мөмкинлек бирә торган индикаторлар

Куелган бурычларны программа чараларын тормышка ашыру юлы белән хәл итү нәтиҗәлелеге ел саен мониторинг, программаның билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләре зурлыкларына ирешү юлы белән бәяләнә:

| № т/б | Индикаторның исеме | Исәпләү методикасы | Чыганак |
|---|---|---|---|
| 1. | Гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән оешкан мәгълүмат-коммуникация компанияләре санын арттыру | N - сан | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, физик культура һәм спорт идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе |
| 2. | Сәламәтлек үзәкләренә кергән мөрәҗәгатьләр санын арттыру, берәмлек | N - сан | Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 19 августындагы 597н номерлы боерыгы белән расланган «Сәламәтлек үзәге эшчәнлеге турында мәгълүматлар» 68 номерлы тармак статистик күзәтү формасы мәгълүматлары |
| 3. | Шәһәрнең белем бирү оешмаларында «Сәламәт туклану» темасына бердәм ачык дәресләр санын арттыру | N - сан | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, физик культура һәм спорт идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе |
| 4. | 3 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган халыкның гомуми | Дз = Чз / Чн х 100, монда: | «Физик культура һәм спорт турында мәгълүматлар» 1- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче затларның өлешен арттыру | Дз - системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче шәһәр халкының чагыштырма авырлыгы,<br>Чз - физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык саны;<br>Чн - статистика мәгълүматлары буенча халык саны | ФК номерлы форма буенча статистик күзәтү мәгълүматлары |
| 5. | Халыкны диспансеризациягә җәлеп итүне арттыру | Күрсәткечнең зурлыгы диспансеризация узган затлар санына карата диспансеризация узарга тиешле затларның факттагы санынан чыгып исәпләнә.<br>$K = \frac{a}{b} \cdot 100$, монда<br>$K$ - кирәкле күрсәткеч,<br>$a$ - процентларда күрсәтергә кирәк булган очраклар саны;<br>$b$ - 100 % итеп кабул ителә торган очракларның гомуми саны | «Республика медицина-мәгълүмат үзәге«"» ДАССУның статистик мәгълүматлары |
| 6. | Алкогольле продукциясен чиктән тыш куллануны киметү максатында чаралар үткәрү | N - сан | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |
| 7. | Тәмәке тартуның таралуын киметү мәсьәләсе буенча чаралар үткәрү | N - сан | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе |

## 5 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны тормышка ашыруга акча бүлеп бирү каралмаган.

## 6 бүлек. Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү

Программаны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү хисап елында аны үтәү йомгаклары буенча һәм гомумән, программаны тормышка ашыру тәмамланганнан соң гамәлгә ашырыла.

Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый нәтиҗәлелек түбәндәгеләр хисабына ирешелә:

- Яр Чаллы шәһәрендә халык сәламәтлеген саклауга һәм яхшыртуга булышлык итә торган ведомствоара мөнәсәбәтләр системасын камилләштерү;
- Яр Чаллы шәһәре халкы тарафыннан сәламәт яшәү рәвеше, физик культура, спорт, сәламәт туклану һәм репродуктив сәламәтлек турында квалификацияле мәгълүмат алу;
- сәламәт туклануны һәм начар гадәтләрдән баш тартуны да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләү системасын булдыру;
- Яр Чаллы шәһәрендә демографик хәлне яхшырту, уртача гомер озынлыгын арттыру, вакытыннан алда үлүчеләр, авырулар санын, халыкның инвалидлашуын киметү өчен шартлар тудыру.

## 7 бүлек. Программа чаралары

Программаның максаты, бурычлары, нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары һәм чаралар буенча финанслау

| Төп чараның исеме | Башкаручылар | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары | Индикаторларның зурлыгы | | | | | | Финанслау (мең сум) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2025 | 2026 | 2027 | 2028 | 2029 | 2030 | 2026-2030 |
| Максат: халык сәламәтлеген, тормыш сыйфатын яхшырту, җәмәгать сәламәтлеге культурасын, сәламәтлеккә җаваплы мөнәсәбәт формалаштыру | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: халыкның сәламәт яшәү рәвеше турында хәбәрдарлыгын арттыру | | | | | | | | | | |
| Сәламәт туклануны, хәрәкәт активлыгын да кертеп, гражданнарны сәламәт яшәү рәвешенә мотивацияләүгә юнәлдерелгән мәгълүмат-коммуникация кампанияләре оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2026-2030 еллар | Чаралар саны, берәмлек | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | 50 | Чара оештыру характерына ия |
| Биналар эчендәге мәгълүмат таблоларында, ведомство плазмаларында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе | 2026-2030 еллар | Видеоэкраннарда күрсәтелгән мәгълүмати материаллар саны, берәмлек | | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| мәсьәләләре буенча социаль рекламаларны трансляцияләү | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: авыруларны профилактикалау | | | | | | | | | | |
| Халык арасында сәламәтлек үзәкләре оештыру | Башкарма комитетның мәгълүмати сәясәт һәм җәмәгатьчелек белән элемтә идарәсе | 2026-2030 еллар | Сәламәтлек үзәгенә мөрәҗәгатьләр саны, берәмлек | | 14300 | 16500 | 17200 | 18000 | 18751 | Чара оештыру характерына ия |
| Шәһәрнең белем бирү оешмаларында «Сәламәт туклану» темасына бердәм ачык дәресләр үткәрү | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2030 еллар | «Сәламәт туклану» ачык дәресләрендә катнашкан балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше | | 2000 | 2200 | 2500 | 2700 | 3000 | Чара оештыру характерына ия |
| Бурычның исеме: физик активлыкны арттыру | | | | | | | | | | |
| Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы, спорт чаралары үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2026-2030 еллар | 3 яшь һәм аннан өлкәнрәк булган халыкның гомуми санында системалы рәвештә физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүче халык өлеше, % | 68 | 69 | 70 | 71 | 71,5 | 72 | Чара оештыру характерына ия |
| Бурычның исеме: профилактик медицина ярдәменнән файдалану мөмкинлеге | | | | | | | | | | |
| Балалар һәм | Башкарма | 2026-2030 | Халыкны план | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | 100 | Чара оештыру |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| өлкәннәр өчен профилактик медицина тикшерүләре үткәрүдә ярдәм күрсәтү | комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе, икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | еллар | буенча диспансеризацияләүгә җәлеп итү, % | | | | | | | характерына ия |
| Бурычның исеме: куркыныч факторларны, шул исәптән тәмәке тартуны, алкоголь һәм наркотик чаралар куллануны, дөрес тукланмауны, физик активлык җитәрлек булмауны киметү | | | | | | | | | | |
| Тематик пресс-конференцияләр, семинарлар, конкурслар, күргәзмәләр үткәреп, ел саен үткәрелә торган «Без сәламәт яшәү рәвеше яклы» массакүләм профилактика акциясе оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе, Башкарма комитетның яшьләр белән эшләү идарәсе, Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, Башкарма комитетның мәдәният идарәсе | 2026-2030 еллар | Акциядә катнашучылар саны, кеше | 47 000 | 48 000 | 48 000 | 48 000 | 48 000 | 48 000 | Чара оештыру характерына ия |
| Тәмәке тартуның таралуын киметү мәсьәләләре буенча чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе, мәгариф идарәсе, яшьләр белән эшләү идарәсе, | 2026-2030 еллар | Чараларда катнашкан балалар һәм яшүсмерләр саны, берәмлек | | 2000 | 2200 | 2500 | 2700 | 3000 | Чара оештыру характерына ия |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе | | | | | | | | | |
| «Спорт - начар гадәтләргә альтернатива» Бөтенроссия акциясенең республика этабын оештыру | Башкарма комитетның мәгариф идарәсе | 2026-2030 еллар | Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның гомуми саныннан акциядә катнашучы укучыларның өлеше, % | 96 | 96 | 96,1 | 96,2 | 96,3 | 96,4 | Чара оештыру характерына ия |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева